**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

2023елның 28 сентябре 93 –РС номер

# КАРАР

## «2023 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2022елның 23 декабрендәге 104-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары кушымтасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Район Советының 2010 елның 23 июлендәге 24 номерлы карары белән расланган Лаеш муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы Нигезләмә белән, Лаеш муниципаль районы Советы **карар чыгарды**:

1. «2023 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2022елның 23 декабрендәге 104-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары кушымтасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (Кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны районның җирле үзидарә органнары белән законлылык, хокук тәртибе һәм үзара хезмәттәшлек буенча комиссиягә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф.Зарипов**

Лаеш муниципаль районы Советының
2023 елның 28 сентябрендәге 93-РС номерлы
карарына кушымта

**«2023 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2022елның 23 декабрендәге 104-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары кушымтасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

| № т/б | Муниципаль мөлкәт исеме | Урнашу урыны | Бина, төзелеш, корылма мәйданы (кв.м) | Җир кишәрлегенең мәйданы (кв.м) | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Торак булмаган бина - мәдәни-спорт комплексы (кадастр номеры 16:24:050601:3299) һәм кадастр номеры16:24:210101:374 булган җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Габишево авыл җирлеге, Габишево ав., Совет ур., 5 й. | 3864,4 | 10345 | 2023 ел дәвамында |
| 2 | Клуб бинасы (кадастр номеры 16:24:150106:391) һәм кадастр номеры 16:24:150106:133 булган җир кишәрлеге | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище ав., Заозерная ур., 21 й. | 595,9 | 571,9 | 2023 ел дәвамында |